# ХОДАЙ БИРГӘН ТАЛАНТ ИЯСЕ

Җыр, моң яратмаган кеше юктыр. Аңа җансызлар гына битараф булып калырга мөмкин. Яхшы җырларны онытылып-онытылып тыңлыйсың, ул сине хисләр дәрьясына ташлый, күңел дөньясын актара, җаныңны сафландыра, уйландыра, әллә кайдан, әлегә үзең дә аңлап бетермәгән нииндидер эчке тирәнлектән чиста, пакь хисләреңне өскә чыгара. Хәтта тормыш авырлыклары да вак нәрсә шикелле булып кала, онытыла, бу минутларда син кичәге җан дошманыңны да кичерергә әзер, кешеләрне кочасың һәм, бөтен җиһанга ишетелерлек итеп: «Бу дөнья нинди матур бит, кеше-лә-ә-р!» – дип кычкырасы килә...

Җәйләүләрдә тугай,  
Тугайларда тургай  
Канатларын җилпи җилләрдә.  
Сине уйлап янам,  
Ник килмисең һаман,  
Күңелләрең синең кемнәрдә?

Халкыбыз талантлары арасында якты йолдызларның берсе булган Зөһрә Сәхәбиева башкаруында «Сине уйлап янам» дигән шушы җырны тыңлагач, күз алдына бөтен матурлыгы белән тургайлы җәй, тугайлы су буйлары һәм беренче мәхәббәтең килеп баса. Хисләреңне ургыта, кайната торган искитмәле җыр! Сүзләре дә, көе дә. Һәм моңы да, аһәңе дә. Аның сүзләрен халык үз күргән шагыйрь Илдар Юзеев язганын белә идем. Ә менә йөрәккә, күңел түренә үтеп керердәй көйне кем язуы турында уйлаганым булмады. Күп еллардан соң гына белдем: аны үзешчән композитор Сафьян Ибраһимов иҗат иткән икән. Аннан соң миңа, шөкер, аның белән аралашып яшәү бәхете дә тиде.

Картаямыни соң йөрәк,  
Маңгайлар сырланса да.  
Үтте яшьлек – җүләрлек, дип,  
Җырларда җырланса да...

Монысын хәтерләдегезме? Без әллә кайчаннан бирле ишетеп-тыңлап килгән «Картаямыни соң йөрәк?!» (Гата Нуруллин сүзләре) дигән җыр бу. Аны Татарстанда гына түгел, татарлар яши торган барлык җирләрдә дә ишетмәгән, белмәгән кеше юктыр. Бу җырны телгә алуга, алдыбызда чын мәгънәдә эстрада йолдызыбыз булган, татар халкының мәшһүр җырчысы Әлфия Авзалова пәйда була. Ул «Картаямыни соң йөрәк?!»не инде күптәннән җырлап килә һәм аны шундый аһәңле, шундый тәэсирле итеп башкаручыны әлегә очратканым да, ишеткәнем дә юк. Ни гаҗәп, һаман туйдырмый бит безне бу җыр! Ә бит инде аннан соң иҗат ителгән, башта ничек яхшы кабул ителгән, җырланган күпме җыр, күңелебездә эз калдыра алмыйча юкка чыкты, онытылды. Моның сәбәбе – көенең җанга ятышлылыгында, күңелебезгә үтеп керә алырлык моңга ия булуында. Димәк, ул да, башка бик күп җырлары кебек үк, Сафьян Ибраһимов тарафыннан йөрәк җылысын, күңел моңнары тирбәлешен кушып, хисләр давылы аша язылган. «Тукта, җыр языйм әле» дип түгел, «моң иҗат итим» дип язылган алар. Аның көйләре – йөрәк түреннән кайнап, тышка бәреп чыккан хисләр ташкыны.

Аның миңа: «Мин җырларымны күз яшьләрем аша, елый-елый язам», – дигәне бар. Ә беләбез бит, хиссез, каты бәгырьле кешедән күз яшьләре чыга алмый – фәкать хисләр ташкыны гына чыгарырга мөмкин аларны. Юк, бу һич тә йомшаклык билгесе түгел! Бу – яңа моңның, яңа көйнең туу мизгелләре! Шатлыклы да, газаплы да мизгелләр алар...

Менә шуннан аның эчке кичерешләрен күз алдына китерегез инде! Димәк, яңа туган көй иң беренче чиратта композиторның йөрәге аша үтәргә, аның үзен елар дәрәҗәгә җиткереп дулкынландырырга, аның үз күңелендә язгы ташкындай кайнарга тиеш икән. Шунсыз көй халык күңелен тибрәндерерлек, йөрәгенә сеңеп калырлык көчкә ия була алмый, сүнә, онытыла. Ә менә Сафьян Ибраһимов иҗат иткән көйләрдә ул көч бар, шуңа күрә аның җырлары халык күңеленә юлны таба да.

Миңа бу искиткеч гади, тыйнак кеше белән якыннанрак танышырга мөмкинлек булды. Ничектер бер мәртәбә аны газета-журнал редакцияләре урнашкан Матбугат йортының коридорында күреп: «Бер шигыремә көй язып карамассыңмы?» – дияргә батырчылык иттем. Ул шундук минем белән «Чаян» журналы редакциясенә (шунда эшли идем) керде, шигырьне укып карады, тик ошатмады, «бу тапталган тема» кебегрәк сүз әйтте. «Җыр буласы шигырь үзе көй сорап торырга тиеш ул!» – диде. Нәтиҗәдә берничә көннән ул миңа: «Көй туды бит! Төнге сәгать өчтә...» – дип шалтыратты. Аннары «Балык Бистәсе таңы», «Мәңге сүнмәс утым» дигән шигырьләремә көй язды. Көйләрне иҗат итүгә, телефон аша үзе уйнап, үзе җырлап та күрсәтә ул – Сафьян Ибраһимов яхшы җырчы да иде әле! Ул үзе башкаруында җыр кассетасы да чыгарды.

Ә баянда ничек моңлы итеп уйный иде ул! Күңел туларлык итеп, өздереп. Бу җәһәттән шунысын да әйтеп китәргә кирәк: шул баянын 1948 елдан бирле кулыннан төшермәде! Аңа булган кадер-хөрмәтен күрсәгез икән! Яшь баланы баккан сыман карады ул аңа, моң чыганагы буларак чын күңеленнән хөрмәт итте.

Ул кече яшьтән үк үзлегеннән мандолина, аккордеонда уйнарга өйрәнә. Бераз үсә төшкәч, танылган баянчы, укытучы Абдулла Халитовтан дәресләр ала. Җиде елга якын Казандагы Укытучылар йортында – баянчы, ике ел Баулы Мәдәният сараенда сәнгать җитәкчесе булып эшли. Аннары аны Күчмә театрга эшкә чакыралар, ул монда баянчы, артист, музыка бүлеге мөдире вазифаларын башкара. Шушы театр төркемнәре белән Татарстанның барлык почмакларында диярлек була. Көйләренең халыкчанлыгы, халык күңеленә тиз барып җитүе дә шуннан килә торгандыр, мөгаен.

Шунысын да әйтеп китим, Сафьян Ибраһимов бернинди махсус уку йортында да укымаган. Аның композиторлык таланты тумыштан килгән. Ә без «ул – чын талант иясе» дип авыз тутырып әйтә алабыз, чөнки талантсыз кеше күбесен яратып җырлый, исе китеп тыңлый торган йөзләгән җыр яза алмый! Хәзер дә күп кенә күренекле җырчыларыбыз аның җырларын яратып башкаралар. Без аларны яратып тыңладык һәм тыңлыйбыз, алардан рухи азык алабыз, хисләргә байыйбыз.

***Әхәт Сафиуллин,***
*язучы, Татарстан Республикасының*
*атказанган мәдәният хезмәткәре*

* * *

Миңа композитор Сафьян Ибраһимов белән күп еллар, концертлар куеп, дөнья әйләнергә туры килде. Без аның белән кайда гына булмадык та нинди генә юл газапларын кичмәдек. Сафьян үзенең шаян, мәзәкчән, нечкә күңелле, җор холкы белән безнең күңелләрне күтәреп, алдагы көннәргә өмет чаткылары уята торган иде.

Минем дә репертуарымда Сафьян Ибраһимовның җырлары бар. Шулай да композиторның миңа үлемсез җыр бүләк иткәнен әйтеп китәсем килә. Бу – композиторның визит карточкасы булган, Гата Нуруллин сүзләренә язылган «Картаямыни соң йөрәк?!» җыры. Шул җыр белән татар эстрада фестиваленең лауреаты булдым. Халык күңеленә кереп, җыр мәңгелек булып калды...

***Әлфия Авзалова,***
*җырчы, Татарстан Республикасының*
*халык артисты*

* * *

Үсмер чагымнан концертларда Сафьян Ибраһимов җырлары яңгыраса, аларны игътибар белән тыңлый идем. Ә радиодан тапшырыласы җырларын көтеп ала идем. Аның үзенчәлекле җырлары, мине үзләренә җәлеп итеп, күңелдә кала иде. Миңа композиторның лирика белән сугарылган патриотик җырлары үзенә генә хас үзенчәлекле бормалары, мелизмнары белән ошый иде. Аның җырларын тыңлап, киләчәктә гаиләбез белән бергәләп Сафьян аганың иҗади дуслары булырбыз дип кем уйлаган?

Миңа һәм ирем Хәйдәргә (халкыбызның бөек җырчысы Хәйдәр Бигичев) Сафьян аганың үтә дә саф күңелле, музыка сәнгате дөньясында фанатларча бирелеп, туктаусыз хезмәттә булуы ошый иде. Концертлар репертуарында композиторның матур җырлары яңгырап тора. Шулар арасыннан «Сине уйлап янам» (И. Юзеев сүзләре) һәм «Яшьлегем кайтавазы» (Г. Мөхәммәтшин сүзләре). Бу җырлар Татарстан Дәүләт радиосы фондына керделәр.

***Зөһрә Сәхәбиева-Бигичева,***
*җырчы, Татарстан Республикасының*
*халык артисты*

* * *

Гомере буе күңеле «моң» дип аталган сихри дөнья белән серләшүче һәм шуның белән яшәүче Сафьян ага Ибраһимовның җырларына мин инде күптән гашыйк. Шуңа күрә ул минем иң якын иҗади дустым иде. Күп еллар бергә җырлар иҗат иттек. Сафьян абый һәрбер шигырьне дикъкать белән укып, үз фикерен әйтә. Әгәр укылган әсәр күңел түренә үтә, аны дулкынландыра икән, андый шигырьгә җыр иҗат итәлә. Бик таләпчән композитор иде. Бигрәк тә башлап язучы авторларга игътибар итә, «аларда заман яңгырашы, яңа караш, яңа тема, яңа сүз бар» ди иде.

Үзе Казан шәһәрендә туып үссә дә, иҗатында авыл тематикасына язылган күпсанлы җырлар урын алган. Композиторның концертлар белән авылларда

булганда аның табигатен күреп, белеп, шул мизгелләрне, кичерешләрне нотага салып, моңлы, матур җырлар язуына сокланасың. Шуңа күрә дә Сафьян аганың җырларын бүгенге көндә танылган җырчылар башкаралар.

***Фердинант Гайсин,***
*шагыйрь, Татарстан Республикасының*
*атказанган укытучысы*

* * *

Сафьян абыйның күңеле мәңгелек моң белән янды. Өлкән буын композиторларның, музыкантларның, гомумән, сәнгать әһелләренең иң яхшы сыйфатларын үзенә җыйган шәхес ул.

Минем репертуарымда композиторның җырлары бар. Күбрәк башкарыла торган җырлардан: «Буласы булган инде» (Р. Миңнуллин сүзләре), «Мамадыш вальсы», «Ай нурлары» (Ә. Гадел сүзләре) һ. б.

***Айдар Габдинов,***
*җырчы, Татарстан Республикасының*
*атказанган артисты*

# Авылым урамы

*Камил Сәгъдәтшин* сүзләре




Мин – ачылып килгән чәчәк,
Син дә бөредә генә.
Кулларыңа кагылу кая,
Киләм күрергә генә.

К у ш ы м т а:

Авылым урамы кыска:
Бар булганы җиде өй.
Һаман яңгырый күңелдә –
Нинди моң бу, нинди көй?

Сине башкалар үпкәнгә
Рәнҗүем күптән үткән.
Яшьлекнең җыры кыска, дип
Әйтмәгез генә бүтән.

К у ш ы м т а.

Югалтмас өчен ярыңны,
Кыюрак булу кирәк.
Безнең яшьлекне сагынып
Моңлана һаман тирәк.

К у ш ы м т а.